# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14 ноябрь 2025 ел** **№1**

««Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе нигезендә,, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә 8.30 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2026 елда 350 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлар; тыл хезмәтчәннәре; көндезге бүлек студентлары; хәрби хезмәт һәм контракт буенча үтүче гражданнар; мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:
1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуга хезмәт күрсәтү);
2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү; (ЗИЛ-131 автомобиле: ягулык-майлау материаллары, запас часть);
3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту ; (кардан чистарту,чуп улэннэрен чабу, юлларны грейдировкалау, МТЗ-82: ягулык-майлау материаллары, түләү, запас часть);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 23 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 12 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 12 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.
2. «2026 елда 350 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга

юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:
1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуга хезмәт күрсәтү);
2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү; (ЗИЛ-131 автомобиле: ягулык-майлау материаллары, запас часть);
3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту ; (кардан чистарту,чуп уләннәрен чабу, юлларны грейдировкалау, МТЗ-82: ягулык-майлау материаллары, түләү, запас часть);

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче — Р.Н. Дәүләтҗанов